СОВЕТ СТАРОЧУРИЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ЧҮРИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

ул. Новая, д.52, с. Старое Чурилино, Арский муниципальный район, 422014

Яңа урамы, 52 нче йорт, Иске Чүриле авылы, Арча муниципаль районы, 422014

Тел. (84366)57-3-48, 3-06-09 факс (84366)57-3-48, 3-06-09 E-mail: Schur.Ars@tatar.ru.

**Иске Чүриле авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**«29» сентябрь 2017ел** **№ 40**

**Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Арча муниципаль районының Иске Чүриле авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны билгеләү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Иске Чүриле авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Иске Чүриле авыл җирлеге башкарма комитетының 2017 елның 18 сентябрендәге 33 номерлы «референдум үткәрүне оештыру турында» гы Карары, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Советының 2017 елның 22 сентябрендәге 39 номерлы «референдум үткәрүне оештыру турында» гы карары нигезендә Иске Чүриле авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Иске Чүриле авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсәләсе буенча җирле референдум уздыруны 2017 елның 19 ноябренә билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны расларга:

«2018 елда Иске Чүриле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә (түләү күләме 150 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, 70 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш,) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү гә җибәрү белән килешәсезме?:

1. Авыл җирлеге чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:

- Штерә, Иске Чүриле авылларында янгын гидранты урнаштыру.

2. Авыл җирлеге чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

-торак пунктларда автомобиль юл-урам челтәреннән вак таш сатып алу, нигез һәм юл өслеге салу буенча хезмәтләр күрсәтү; Иске Чүриле авылы, Зеленая урамы (52А, 56А, 8-22 йорт); Иске Чүриле авылы, Яңа урамы (34-48); Ашабаш авылы, Комсомол урамы (150 м); Михайловка п, Түбән урамы (500 м); Штерә авылы, Совет урамы (67-93 йорт).

3. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (шул исәптән урамнарны яктырту):

- Штерә, Ермоловка авылларында урамнарны яктырту.

әйе юк

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

әйе юк

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга: Татарстан Республикасы, Арча районы, Иске Чүриле авылы, Яңа ур., 52; ТР, Арча районы, Штерә авылы, Совет ур., 30; ТР, Арча районы, Ашабаш авылы, Комсомол урамы, 4а; ТР, Арча районы, Венета авылы, Үзәк урамы, 13.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Иске Чүриле авыл җирлеге башлыгы Г.Р.Заһидуллина